КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 30 октябрь г.Казань № 978

Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарында остазлыкны оештыру турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәтендә остазлык турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2019 елның 7 октябрендәге 1296 номерлы карарын гамәлгә ашыру максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнарына Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәтендә остазлык турында нигезләмәне раслау хакында» 2019 елның 7 октябрендәге 1296 номерлы карары белән расланган Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәтендә остазлык турындагы нигезләмә (алга таба – Остазлык турында нигезләмә) нигезендә остазлыкны гамәлгә ашыру эшен оештырырга.

2. Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнарына муниципаль хезмәттә остазлыкны оештырганда Остазлык турындагы нигезләмәгә таянырга тәкъдим итәргә.

3. Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма хакимият органнарына, шулай ук Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнарына тәкъдим итәргә:

остазларны билгеләүне Татарстан Республикасының иң абруйлы, тәҗрибәле һәм нәтиҗәле дәүләт граждан хезмәткәрләре һәм Татарстан Республикасында муниципаль хезмәткәрләр (алга таба – хезмәткәрләр) арасыннан гамәлгә ашырырга;

хезмәткәрнең остаз сыйфатында эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген аеруча мөһим һәм катлаулы биремнәрне үтәгән өчен премия биргәндә исәпкә алырга кирәк;

Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарының һәм Татарстан Республикасы җирле үзидарә органнарының «Интернет» мәгълүмат-

телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтларында иң яхшы остазлар турында мәгълүмат урнаштыру эшен оештырырга.

4. «Казан (Идел буе) федераль университеты» югары һөнәри белем бирү федераль дәүләт автоном мәгариф учреждениесенең Дәүләт һәм муниципаль идарә югары мәктәбенә хезмәткәрләрнең һөнәри үсеше буенча чараларны гамәлгә ашырганда Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте ветераннарын, Татарстан Республикасында муниципаль хезмәт ветераннарын җәлеп итәргә.

5. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнарында остазлык турындагы нигезләмәне раслау турында" 2014 ел, 11 июнь, 402 нче карары үз көчен югалткан дип танырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин